**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Инвалидлар эшләре советы составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Инвалидлар эшләре советын төзү турында» 2010 елның 31 декабрендәге ПУ-908 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 30 апрелендәге ПУ-247 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1015 номерлы, 2016 елның 2 сентябрендәге ПУ-786 номерлы, 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2018 елның 14 маендагы ПУ-369 номерлы, 2019 елның 2 февралендәге ПУ-59 номерлы, 2019 елның 21 августындагы ПУ-479 номерлы, 2019 елның 25 ноябрендәге ПУ-707 номерлы, 2021 елның 14 гыйнварындагы ПУ-3 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 16 маендагы 302 номерлы, 2023 елның 25 августындагы 589 номерлы, 2024 елның 18 гыйнварындагы 26 номерлы һәм 2024 елның 30 мартындагы 229 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Инвалидлар эшләре советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составына түбәндәгеләрне кертергә:

Кабыш Евгений Григорьевичны – «Әфганстан һәм махсус хәрби операцияләр ветераннарының Россия берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы буенча төбәк иҗтимагый оешмасы рәисен, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының Яшьләр эшләре, ихтыярыйлыкны һәм патриотик тәрбия бирүне үстерү комиссиясе әгъзасын (килешү буенча);

Удачина Гүзәл Любис кызын – «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм күрсәтү дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалы җитәкчесен (килешү буенча);

б) Совет әгъзалары вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

И.М. Егоровның – «Ак Барс» холдинг компаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры, Әфганстан Республикасында хәрби хәрәкәтләр ветераннары һәм Төньяк-Кавказ төбәге территориясендә коралллы конфликтларда һәм террорчылыкка каршы операцияләрдә катнашучылар мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы координация советы рәисе (килешү буенча)»;

Л.Р. Сафинның – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 15 август
№ 623